*/Без тарихта эзлебез!/*

### *Элеккеге мәктәп-мәдрәсәләрдә укытылган җәгърафия дәреслекләре*


Азия харитасы (картасы)

Гәзитебезнең алдагы саннарында элеккеге заманнарда әби-бабаларыбыз укыган төрле китаплар һәм дәреслекләр турында мәкаләләр биргән идек. Әлеге теманы дәвам итеп, бу язманы җәгърафия дәреслекләренә багышларга булдык.

Әле урта гасырларда ук мөселман галимнәре һәм сәяхәтчеләре география фәне үсешенә зур өлеш кертүгә карамастан, безнең татарларда ул фәнне мәктәп-мәдрәсәләрдә укыту бары тик XIX гасырның 80нче елларында гына кертелә башлый. Шул елларда җәгърафия буенча беренче дәреслекләр дә басыла башлый. Бу фән буенча дәреслекләр язу белән дистәгә якын галим-мәгърифәтчеләр шөгыльләнә (Габделгаллӛм Фәезханов – "Гомуми җәгърафия рисаләсе", 1888 / Каюм Насыйри – "Истыйляхате җәгърафия" 1890, "Ысулы җәгърафия кәбир" 1894 / Гобәйдулла Буби – "Мохтәсар җәгърафияи гомуми", 1898; "Кечек җәгърафия", 1910 / Шиһаб Рәхмәти – "Җәгърафия гомумия", 1899 / Фатих Кәрими – "Мохтәсар җәгърафия", 1899, "Җәгърафия гыйммрани" 1909 / Мөхәммәтрәхим Ханәфи – "Җәгърафия әҗмали", 1900 / Харис Фәйзи – "Әүвәле җәгърафия"; "Мәдхәле җәгърафия", 1906; "Тәгълиме җәгърафия", 1911; "Ысул җәгърафия", 1905 / Габдерәшит Фәхретдинов – "Бәләкәй җәгърафия" 1912; "Рәсемле җәгърафия", 1913).

Югарыда телгә алынган дәреслекләрнең кайберләре безнең гарәп язулы иске китаплар тупланмасында да бар. Шулар арасында аеруча яхшы сакланганнары – күренекле педагог һәм журналист Харис Фәйзинең "Мәдхәле җәгърафия" һәм "Тәгълиме җәгърафия" китаплары. (Харис Фәйзи (1871-1933) – медицина профессоры Мидхәт Фәйзуллин белән композитор Җәүдәт Фәйзинең әтиләре, драматург Мирхәйдәр Фәйзинең туганы). Болардан тыш тагын мәшһүр галимнәрдән Фатих Кәриминең "Җәгърафия гыйммрани" һәм Мөхетдин Корбангалиевнең "Дөнья: җәгърафия рисаләсе" дәреслекләре дә бар. Тагын бер җәгърафия китабының 6 битлек фрагменты гына сакланган. Французлар һәм итальяннарга багышланган ике аерым китап җәгърафия фәнен өйрәнгәндә өстәмә әдәбият рәвешендә кулланылган булырга мөмкин.


Җиһәт аслыя (горизонт яклары)

Башлангыч сыйныфлар өчен чыгарылган "Мәдхәле җәгърафия" (географиягә кереш) дәреслегендә урынның планын, географик объектларны, горизонт якларын, төрле кыйтгалардагы табигать шартларын һәм илләрне өйрәнү каралган. Русиянең табигате, сәяси хәле һәм территориаль төзелеше аерым темалар белән китерелә.

Өлкәнрәк сыйныф җәгърафияләрендә төрле илләр һәм халыкларның тормышы тирәнтен яктыртыла. "Тәгълиме җәгърафия" дәреслегенең өченче кисәге Русиядән гайре башка илләрнең табигатен, климатын, халкының милли составын, сәяси һәм административ төзелешен, күренекле шәһәрләрен өйрәтүгә багышланган. "Җәгърафия гыйммрани" китабында төрле илләрнең хуҗалыгы аларның табигате белән бәйләп аңлатыла. Биредә Аурупа дәүләтләренең алга китү сәбәпләре, алар арасында Русиянең торышы, Русия үзенә кушкан Кавказ, Себер, Урта Азия, Польша, Финляндия илләренең империя өчен әһәмияте, колонияләрдән файдалану үзенчәлекләре яктыртыла. Бу дәреслектә демографиягә һәм икътисадка кагылышлы күптөрле сан күрсәткечләре китерелә. Фрагмент хәлендәге җәгърафия дәреслегендә Русиянең төрле тарафларындагы елгалар, күлләр, диңгезләр, таулар аларның климатка тәэсире турындагы темалар урын алган.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы җәгърафия дәреслекләре балаларга дөнья турында ул заман өчен җитәрлек күләмдәге белем бирерлек итеп төзелгән булган.

*Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты*

*/Котлыйбыз!/*



Гыйнвар аенда дөньяга килгән дусларыбыз III сыйныфтан **Хәйруллин Мансурны**, V сыйныфтан **Залиев Илфирны**, VIII сыйныфтан **Закирова Ләйсәнне** туган көннәре белән котлыйбыз. Аларга исән-сау булып, тырышып белем алуларын телибез.

Укытучы **Хөснуллин Фәнис абыйны**, техник хезмәткәр **Сәгдиева Рәмзия** апаны да гомер бәйрәмнәре белән котлап, сәламәтлек, гаилә иминлеге, эшләрендә уңышлар телән калабыз.

**Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе**
**Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина**
**Редколлегия әгъзалары – Асия Нурматова, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Настя Сафеева.**

# Мәктәп хәбәрчесе

**№1 (№72) гыйнвар 2026 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе гәзите*

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**

2026 ГОД ВОИНСКОЙ И ТРУДОВОЙ ДОБЛЕСТИ
ХӘРБИ БАТЫРЛЫК ҺӘМ ХЕЗМӘТ ФИДАКАРЬЛЕГЕ ЕЛЫ

*/Мөхәррир минбәре/*

### *2026 нчы ел – Татарстанда хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы*

2026 ел Татарстанда Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы дип игълан ителде. Бу инициатива төбәгебезнең тарихына, аның халкының батырлыгына һәм тыныч тормыш өчен көрәшкә куйган зур өлешенә зур хөрмәт белдерүне максат итеп куя. Ел дәвамында республикада шушы темага багышланган төрле мәдәни һәм белем бирү чаралары оештырылачак. Бу юнәлештә беренче чиратта, Татарстанның сугыш һәм хезмәт ветераннарын, шулай ук хезмәт алдынгыларын искә алу һәм хөрмәтләүгә юнәлдерелгән эшләр алып барылачак. Төрле күргәзмәләр, очрашулар, документаль фильмнар күрсәтүләр, патриотик рухтагы концертлар һәм тематик лекцияләр узачак.

Мәктәбебездә дә хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы төрле чаралар үткәрү планлаштырыла. Беренчедән, авылдашларыбызның авыр сугыш елларында һәм аннан соңгы чорның авыр хезмәттә сынатмауларын яшь буынга күрсәтү максатыннан туган ягыбыз тарихын тагын бер өйрәнеп чыгу тиешле булыр. Шулай ук, бу ел яшь буынны Ватанны ярату, ата-бабаларын хөрмәт итәргә өйрәтү өчен махсус дәресләр үткәреләчәк. Бу чаралар укучыларга тарихи вакыйгалар турында тулырак мәгълүмат бирү, батырларыбызның исемнәрен мәңгеләштерү, бүгенге көндә дә хәрби хезмәтнең һәм тыныч хезмәтнең әһәмиятен ассызыклау өчен файдалы булачак.

Бүгенге яшь буынга әби-бабалары үткән тормыш юлларын, алар яшәгән һәм эшләгән шартларны аңлатуы җиңел түгел, әлбәттә. Тик аларга да ныклап хезмәт тәрбиясе бирә алсак иде. Тәрбиянең кайсы гына өлкәсен алып карасаң да, ул хезмәт белән тыгыз бәйләнгән. Әйтик, белем алу, үзеңне әхлаклылык һәм зәвыклылык нормаларына күндерү, ихтыяр көче тәрбияләү – болар барысы да кешенең тырыш хезмәт нәтиҗәсе.

Хезмәт – чыннан да, куәтле тәрбия чарасы булып тора. Хезмәтнең тәрбияви мөмкинлекләре түбәндәге очракларда аеруча ачык күренә дип исәплим: әгәр хезмәт балаларның рухи дөньясына үтеп керсә, бергә эшләү барышында дуслык һәм иптәшлек хисләрен булдырса, эш нәтиҗәсеннән канәгатьләнү хисләрен уятса, ихтыяр көче һәм тырышлык сыйфатларын үстерсә, авырлыкларны җиңеп чыгу шатлыгын тудырса, кызыксынучанлык аркылы әйләнә-тирә дөньябызның ямен күрә белергә өйрәтсә.

Хезмәт-дөньяда бары кешегә генә хас һәм бары тик ул гына лаек булган бәхет ул. Кулыннан эш килә торган тырыш кешеләрнең тормышта бәхетле, матур яшәүләрен һәммәбез күреп тора. Андыйлар нинди генә эшкә тотынмасын, аны җиренә җиткереп башкара. Ләкин кайберәүләр кечкенә генә кыенлыклар алдында да каушап, аптырап, югалып кала, ягъни аларга башка берәүнең ярдәме кирәк. Кеше менә шундый хәлгә төшмәсен, тормыш итүгә һәрьяклап әзерләнсен өчен, аңа балачактан хезмәт тәрбиясе бирү зур әһәмияткә ия.

Шунысы куанычлы, соңгы елларда мәктәпләрдә хезмәт тәрбиясе бирүгә игътибар арта бара. Тәрбия эшчәнлегенең мөһим юнәлеше буларак, профориентациягә зур әһәмият бирелә. Укучылар төрле һөнәр серләренә өйрәнсен, җәмгыятькә файдалы, җитештерүчән хезмәттә катнашсын өчен элеккеге хезмәт дәресләрен кире программага керттеләр. Узган уку елында гына да, хезмәт дәресләрендә куллану өчен шактый күләмдә эш кораллары кайтарылды. Бу ярдәм киләчәктә дә дәвам итер дигән өмет белән яшибез.

Ләкин, кызганычка каршы, баланы хезмәт сөюгә өйрәтү өчен, мәктәптә бирелә торган тәрбия генә җитми. Һәр гаиләдә бала хезмәт күнекмәләрен алып үсәргә тиеш. Хезмәт тәрбиясенә, иң беренче чиратта, гаиләдә нигез салына. Кешене эшкә күнектерү – иң мәшәкатьле вазифаларның берсе. Хезмәткә мәхәббәт бары тик үз кулы белән эшләү барышында гына барлыкка килә ала. Әшне бала бик бәләкәй чакта үз-үзенә хезмәт күрсәтүдән башласа, үсә төшкән саен, бу өлкә дә киңәя бара. Көндәлек тормышыбызда көнкүреш хезмәте бик зур урын алып тора. Өй җыештыру, кер юу, кибеткә бару, аш-су әзерләү, йорт тирәсен тәртиптә тоту, малларны карау һәм башка бик күп эшләрне көн саен эшләргә туры килә. Баланы көндәлек хезмәтне башкарырга җәлеп итеп, ата-ана аны киләчәк мөстәкыйль тормышка әзерләп кенә калмый, оешканлык, активлык, ярдәмчеллек һәм якын кешеләрен кайгырту гадәтләрен дә тәрбияли.

Гомумән, быелгы хезмәтне данлау елы чаралары, үткәннәр турында хәтеребезне яңартып, бүгенге каһарманнарны танып, киләчәк буыннар өчен яхшырак тормышны булдырырга тагын да зуррак этәргеч бирер дигән өметтә калыйк.

*Фәнүзә Гафиятуллина, баш мөхәррир*



/Мәктәп тормышы/

## Гыйнвар аенданиләр булды?

Быелгы гыйнвар аенда күп укырга туры килмәде. Айның яртысы диярлек кышкы каникуллар белән үтсә, тагын бер атна дәвамында көннәр бик нык суыну һәм күп укучыларның авыруы сәбәпле укулар булмады. Шуңа да карамастан, узган айда мәктәптә булып узган вакыйгаларны билгеләп үтәргә булдык.

23 ноябрь көнне укучыларыбыз әйләнә-тирә дөнья буенча **"Эверест"** дип аталган республика олимпиадасында катнашканнар иде. Инде менә бу айда бәйгенең уңышлы нәтиҗәләре дә килде. Башлангыч сыйныф укучыларыннан **Гафиятуллина Руфинә** (IV сыйныф), **Хәйруллин Мансур** (III сыйныф) һәм **Нурматов Яхья** (II сыйныф ) – призер исеменә лаек булдылар. **Нурматова Мәдхия** (III сыйныф) сертификат белән бүләкләнде. Укучыларга киләчәктә дә уңышлар телибез.





Гыйнвар аеның соңгы якшәмбесе "Халыкара Интернетсыз көн" буларак билгеләп үтелә. Бу көннең максаты –кешеләрне компьютерлардан тулысынча читкә юнәлтү, бер генә көнгә булса да "реаль дөньяда" яшәү, башка кешеләр, туганнар белән аралашу, үзеңне яраткан эшеңә багышлау. Шул уңайдан мәктәбебездә тәрбия буенча директор киңәшчесе Гөлфия апа Әхмәтҗанова башлангыч сыйныфлар өчен "өстәл уеннары оазисы" дигән чара оештырды. Өлкән сыйныф укучылары анкета тутырдылар. Интернетсыз көн кызыклы һәм файдалы узды, ә оештырылган чаралар тере аралашудан да яхшырак нәрсә юклыгын тагын бер кат исбатлады.

"Мультфильмнарны ничек ясыйлар?" "Мөһим нәрсәләр турында сөйләшүләр" циклындагы дәреснең темасы шулай дип атала иде. Дәресләрне 1-9 сыйныф җитәкчеләре үткәрде. Башлангыч сыйныф укучылары танылган мультфильмнардагы музыкаль әсәрләрдән өзекләр тыңладылар. Балалар кроссвордлар чиштеләр һәм интерактив биремнәр башкардылар. Шулай ук мультфильм персонажларының ничек барлыкка килүен һәм аларны актерлар ничек яңгыратуын белдек. Өлкән сыйныф укучыларына сәнгатьнең бер урында тормавы турында искә төшерделәр. Бүген рәсемле кадрларга алмашка яңа технологияләр килә.



25 гыйнварда **"Россия студентлары көне"** билгеләп үтелә. Бу көн алдыннан безнең мәктәптә Россия студентлары көне тарихы турында презентацияләр карау оештырылды. Кече мәктәп укучылары, "профессионаллар шәһәре" проектында катнашып, ватманда коллаж ясадылар. Анда үзләрен киләчәктә кем булачакларын күз алдына китерделәр. 8-9 сыйныфлар "Студент көне – Татьяна көне" интеллектуаль викторинасында катнаштылар. Бу чара кызыклы гына түгел, студентлар тормышы турында белемнәрне киңәйтергә дә мөмкинлек бирде. Әлеге чараларның максаты – укучыларның һөнәри белем алуга кызыксынуын арттыру, шулай ук аларны булачак студент тормышына әзерләү.

Ленинград блокадасы тәмамлануын билгеләп үтү кысаларында 6-8 сыйныф укучылары белән **"Бу онытылмас 900 көн һәм төн"** темасына сыйныф сәгатьләре үткәрелде. Әлеге чара барышында укучылар чолганышта калган шәһәр халкы кичергән фаҗигале хәлләр, һәм гомумән, Бөек Ватан сугышы тарихына кагылышлы күп гыйбрәтле белемнәр алдылар.

***Вакыйгаларны редколлегия әгъзалары туплады***

/Безнең спорт/




Гыйнвар ае ялларында, гадәттәгечә, районыбызда шашка-шахмат ярышлары булып узды. 6 гыйнвар көнне Кече Сөнчәле авылы клубында шушы авылдан чыгышлы зур галим, академик С.А.Абруков истәлегенә багышланган ачык шахмат турниры оештырылды. Безнең шахматчыбыз **Гафиятуллин Фаил** дә бу бәйгедә катнашып лаеклы I урынны яулады.

Фаил, шулай ук, 7 гыйнварда үткәрелгән В.А.Горбунов истәлегенә багышланган ачык турнирда да җиңү яулады. Укучыбызны уңышлары белән котлап, киләчәктә дә сынатмавын теләп калабыз.



/Укучылар иҗаты/

## Бабамның балачагы

Сугыш – коточкыч сүз. Ул тормышны җимерә, кайгы һәм газаплар китерә. Сугыш баланың балачагын урлый, сабыйлыктан да чыкмаган килеш "тәртә арасына" кертеп бастыра. Без ул хәлләрне китаптан укып, олылардан ишетеп кенә беләбез. Ә минем Шәүкәт бабама бу хәлләрне үз башыннан кичерергә туры килә. Ул туганчы ук әтисен югалта. Сугыш башланганда аңа нибары биш яшь була. Һәм хәзергә кадәр, ул елларны искә төшергәндә, аның күзләренә яшьләр җыела.

Шәүкәт бабай үзенең авыр балачагы турында бик күп сөйли. Миңа аеруча аның иң коточкыч нәрсә – ачлык турында сөйләгәне нык тәэсир итте. Карт бабай ул елларны туйганчы ашау бәхете бик сирәк була иде, ди. Черек бәрәңгедән пешергән кабартмаларны бабай хәзер дә нинди дер бик тәмле ризык ашаган шикелле сөйли. Ул заманнарда ул чыннан да иң тәмле һәм туклыклы ризыкларның берсе булган бит инде. Ул черек бәрәңгене табу өчен күпме җир казыганнар алар. Ә исән бәрәңге күп булган вакытта, ашарга бәрәңгене әрчеп пешергәннәр. Калынрак әрчелгән кабыкларны мич алдына утырып, алга күмер тартып шуны кыздырып ашый идем, ди бабай. Ул безнең хәзерге чипсылар кебек булгандыр инде аңа.

Җәйләрен иң еш ашала торган ризык – кычыткан ашы булган. Аның кычыткны да гел булып тормаган бит әле, балалар чыккан берсен җыеп бара торган булганнар. "Без, бала-чага, кычытканны күп итеп җыеп куя идек, әниләр чормада кышкылыкка киптерен тә куя иделәр", – дип әйтә бабай. Кышын ул кипкән кычытканны ашка куертыр өчен сала торган булганнар. Өйдә ашарга һич бернәрсә дә калмаса, биш яшьлек бабам авыл буйлап ашарга эзләп чыгып китә торган була. Ул әле дә Миңлебай бабайны һәм аның карчыгын яратып, җылы сүзләр белән искә ала. "Тәлинкә тутырып катык салып бирә иделәр. Мин аулак тыкрыкка кергәч аның яртысын кызыгып эчә идем. Әнигә ялгыш түктем дип әйтә идем", - дип сөйли бабам. Яман ачлыктан интеккән бала ничек эчмәсен инде ул тәмле катыкны? Кайбер вакыт кечкенә генә кисәк сары май да бирә иделәр, ди. Анысын, күпме генә кызыкса да, бабам ашамаган, өйдәгеләргә алып кайтып тапшыра торган булган. Хәзергә заманда күз алдына китереп булмаслык хәл, кечкенә бала гаилә туклыгын кайгыртып ризык эзләгән...

Әби белән әни күп итеп кәҗәләр дә асырап карадылар, дип сөйли бабай. Кәҗә сөтеннән май ясап, Биләр базарына сатарга йөргәннәр. Базарга бабай да ияреп баргалаган, чөнки май саткан акчага аңа әнисе көтеп алган кабартмасын алып бирә торган булган. "Ул арыш кабартмасын ике генә каба", – идем ди. Ике кабуда бетә торган кабартма өчен җәяүләп унике километр юл үткән кечкенә генә бала. Бер кадак май ун сум, ә бодай онының поты сигез йөз сум иде, дип искә төшереп үтте бабай. Ул заман өчен ул бик зур акча булган.

1941-1942 нче еллар бик салкын булган, утын бик күп кирәккән. Кечкенә генә бабай әбисенә ияреп кышкы салкында аягына чабата киеп, чана тартып урманга йөргән. Чыбыклар җыя идем, дип сөйли ул. Әгәр кайтканда лесникка очрасаң, утыныңны да, балтаңны да алып калып. кечкенә чанаңны да тапап китә торган булган. Җәйгә чыккач зелпе кабыгын җыйдырганнар. Күп итеп җыеп бирсәң, күпмедер метр чүпрәк биргәннәр. Ул чүпрәктән әбисе бабама киемнәр теккән. Уйлап карасаң, бабай 5-9 яшьлек вакытта үзенә, гаиләсенә ризык һәм кием табуда зур өлеш керткән бит. Берсендә шулай зелпе кабыгы җыеп кайтышлый, бабайның әнисе Чуаш Майнасы кырына чәчелгән борчакны кызыгып җыйган. Өйдә бит ашарга сораучы балалар бар! "Бервакыт агроном килеп чыкты, әнинең кыстырып куйган кузакларын йолкып алды. Үзен атына бәйләп Чуаш Майнасының идарәсенә алып китте", – ди бабай. Бабам әнисе өчен бик курыккан , төнлә дә аның янына хәл белергә чыккан. Бәхеткә каршы, әнисен иртән кайтарып җибәрәләр.

Каһәр суккан сугыш күпме сабыйның балачагын урлаган бит. Ул заман балаларын ныклы, түземле итеп тормыш үзе тәрбияләгән. Авырлыкны җиңәргә дигән уй белән түгелдер, нәкъ тормыш кушканча эшләп, авыр хезмәтне гадәти итеп башкарганнар. Аларның үрнәген бүген ничек кенә тырышсак та, башкарып чыгып була торган түгел. Булсын дип тә теләмибез, безгә бүген бәхетле тормыш бирелгән. Тик өлкәннәрнең балачагын белеп, аларга кадер-хөрмәт күрсәтеп кала алсак иде, дип телим. Алар кебек авырлыктан курыкмыйча, һәр эшне җиңәргә өйрәнеп үссәк иде. Тәвәккәл таш яра, дигән бабайлар. Нәкъ менә шул сыйфатны тәрбиялисе иде, диеп әйтәсем килә.

Һәр кич саен минем бабам тынычлык һәм барлык балалар өчен бәхетле балачак өчен дога кыла. Ул үзе кичергәнне тагын кемнеңдер кичерүен теләми. Бабай безнең тыныч тормышның һәр көнен кадерләвебезне тели.

Мин бабамның сөйләгәннәрен тыңлыйм да, үземне бик бәхетле бала дим. Чөнки минем янымда әнием, әтием бар, өстәлләр ризыктан сыгылып тора, матурдан-матур киемнәр киям. Барлык балаларның да минем кебек бәхетле яшәвен телим! Аларның әниләре, әтиләре, уенчыклары булсын, һәм алар сугышның нәрсә икәнен беркайчан да белмәсеннәр иде. Балачак – иң матур, һәм шул ук вакытта, иң кыска да чор бит ул, аны бернинди афәт тә дә бозмасын иде!

***Ләйсән Закирова, VIII сыйныф укучысы***